| | | |
|---|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**БИКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**БИККОЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Биккол авылы **КАРАР**

«18» июль 2025 ел 1

Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикул авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. 2025 елның 29 июлендә 13 сәгать 00 минутка Биккол авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авылы җирлегендә яшәүче барлык кешеләр өчен үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авылында яшәүче гражданнар өчен Биккол авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

"Элек расланган гражданнар җыенына чыгарылган сорауга үзгәрешләр кертүгә сез ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авылы җирлеге Биккол авылы торак пунктындагы 12.11.2024ел, № 1 гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авылы җирлеге Биккол авылы торак пунктындагы 12.11.2024ел, № 2 гражданнар җыенының карары

аны түбәндәге редакциядә расларга:

«Нурлат муниципаль районының Биккол авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су бирүне тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Биккол торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кышкы карап тоту).»

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» http://pravo.tatarstan.ru мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авылы мәгълүмат стендларында, гражданнар җыенын уздыру датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Әхмәтшина